## 2 нче сыйныф (татар төркеме ) әдәби укудан 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 2 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 70 сәгать.Арадаш аттестация –тест формасында.

Программа: ”Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын укыту программасы (*татар балалары өчен*)төзүче-авторлары: Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева Казан -2011

Дәреслек . Р. Х. Ягъфәрова “Уку китабы” Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2013 ел. рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2нче сыйныфы өчен

**2 нче сыйныфта әдәби укудан төп бурычлары түбәндәгеләр**

укучыда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту;
әдәби уку тәҗрибәсе булдыру;
үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;
татар әдипләренең иң яхшы әдәби әсәрләре белән танышу;
әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, уку тизлеге нормаларына сыешу;
татар халык авыз иҗаты әсәрләрен белү, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү;
текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәтү;
әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;
халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак кабул итәргә күнектерү;

**Предмет буенча укучылар үзләштерергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре**

текстның нәрсә турында булуын аңлата белергә
текстны өлешергә тарката белергә
укытучы ярдәмендә план төзи һәм шуның буенча текстның эчтәлеген сөйли белергә
башка кеше укыганны тыңлап, эчтәлекне сөйли белергә тиеш
халык авыз иҗаты һәм аның жанрларын аеру
әкиятләрдәге кызыклы сюжет һәм композиция
табышмак, мәкаль һәм әйтемнәр
аларга мисаллар китерә белү
әдәби әсәрләрдә гомумиләштерелгән образлар, аларның эш- гамәлләре турында сөйли белү

## 2 нче сыйныф (татар төркеме ) татар теленнән 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 3 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 105 сәгать. Планлаштырылган контроль эш- 4.(Арадаш аттестация –грамматик биремле контроль диктант)

Программа: “Рус телендә урта(тулы) гомуми бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы ”(татар балалары өчен) төзүче –авторлары :Ф.Ф.Харисов,Ч.М.Харисова, В.А.Гарипова, 2011

Дәреслек . Татар теле: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен дәреслек/ татар балалары өчен. Ф.Ф.Харисов, , Ч.М.Харисова.,Е.А.Панова–Казан:Мәгариф-Вакыт нәшрияты , 2013

**2 нче сыйныфта татар телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр**

Гамәли максатка ирешү өчен,укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру;
диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү;
төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү;
дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;
татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү

**Предмет буенча укучылар үзләштерергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре**

2 нче сыйныфны тәмамлаганда, татар алфавитын яттан белү. Сүзләрне алфавит тәртибендә язу. Калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны аера белү; ъ, ь хәрефләре булган сүзләрне дөрес уку һәм язу; я, ю, е хәрефләрен дөрес язу.

Татар телендә сүз басымын кую, рус сүзләре белән чагыштырып күрсәтү. Сүз төркемнәреннән исем, фигыль, сыйфатларның мәгънәләрен аңлап, җөмлә эченнән табып әйтү. Исемнәрнең берлек, күплек сан формаларын аеру. Фигыльнең юклык, заман кушымчаларын билгеләү. Җөмләнең баш кисәкләрен билгеләү, аларның урнашу тәртибен аңлату. Җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре дигән төшенчәне аеру

**Аннотация к рабочим программам.**

**2 класс. Татарский язык. Литературное чтение.**

Количество часов в неделю: 3-татарский язык, 2-литературное обучение

Количество часов в год: 105-татарский язык, 70- литературное обучение

Учебно-методический комплекс: Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева “ Күңелле татар теле” (Увлекательный татарский язык).Учебник по татарскому языку и чтению для русскоязычныхучащихся 2 класса четырёхлетней начальной школы на основе концепции коммуникативной технологии Е.И.Пассова. Допущено МО и Н РТ. Казань, издательство “ Татармультфильм” 2013 год.

**3 класс. Татарский язык. Литературное чтение.**

Количество часов в неделю: 3-татарский язык, 3- литературное обучение

Количество часов в год: 105- татарский язык, 105- литературное обучение

Учебно-методический комплекс: Р.З. Хәйдәрова, Н.Г. Галиева “ Күңелле татар теле”(Увлекательный татарский язык) в двух частях.Учебник по татарскому языку и чтению для русскоязычных учащихся 3 класса четырёхлетней начальной школы на основе концепции коммуникативной технологии Е.И.Пассова. Допущено МО и Н РТ. Казань, издательство “ Татармультфильм” 2013 год.

**4 класс. Татарский язык. Литературное обучение.**

Количество часов в неделю: 3-татарский язык, 2- литературное обучение

Количество часов в год: 105- татарский язык, 70- литературное обучение

Учебно-методический комплекс: Р.З. Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова “ Татар теле” (Татарский язык) в двух частях.Учебник для образовательных организаций начального общего образования с обучением

на русском языке (для изучающих татарский язык) на основе концепции коммуникативной технологии Е.И.Пассова. Допущено МО и Н РТ. Казань, издательство “Татармульфильм” 2014год.

Задачи организации учебной деятельности:

1)воспитание интереса к татарскому языку как к средству общения ;

2)воспитание любви и уважения к татарскому языку;

3) освоение знаний о татарском языке, его устройстве и функционировании в различных сферах и ситуациях общения; об основных нормах татарского литературного языка; о татарском речевом этикете;

4) обучение правильному чтению и письму , навыкам диалогической речи , простой монологической речи;

5)обучение пересказу небольших текстов;

6)изучение грамматики, лексики, синтаксиса татарского языка согласно рабочим программам

Формы контроля:

| Класс | Предмет | Контрольная работа | Тест | Диктант | Изложение | Сочинение |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | Татарский язык | 4 | 5 | 2 | | |
| 2 | Литературное чтение | 2 | 5 | | | |
| 3 | Татарский язык | 1 | 5 | 2 | 1 | 1 |
| 3 | Литературное чтение | 3 | 3 | | | |
| 4 | Татарский язык | 3 | 3 | 1 | 1 | 2 |
| 4 | Литературное чтение | 4 | 1 | | | |

**Количество часов в неделю: 3-татарский язык, 2- литературное обучение**

## 3 нче сыйныф (татар төркеме ) әдәби укудан 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 3 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 105 сәгать.Арадаш аттестация –тест формасында.

Программа: ”Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын укыту программасы (*татар балалары өчен*)төзүче-авторлары: Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева Казан -2011

Дәреслек . Р. Х. Ягъфәрова “Уку китабы” Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2013 ел. рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3нче сыйныфы

**2 нче сыйныфта әдәби укудан төп бурычлары түбәндәгеләр**

укучыда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту;
әдәби уку тәжрибәсе булдыру;
үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

татар әдипләренең иң яхшы әдәби әсәрләре белән танышу;
әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, уку тизлеге нормаларына сыешу;
татар халык авыз иҗаты әсәрләрен белү, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү;
текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәтү;
әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;
халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак кабул итәргә күнектерү;
төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисе тәрбияләү.

**Предмет буенча укучылар үзләштерергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре**

тексттагы вакыйга яки төп персонаж буенча аңа исем куя белү;
укытучының соравына тексттагы вакыйга яки эпизодны кулланып җавап бирә белү;
берничә текстны темасы буенча берләштерә белү;
укылган бүлеккә план төзи белергә һәм шуңа язма җавап әзерли белү.
лирик шигырьләр, шагыйрьнең хис-тойгылары,сурәтләү чаралары, чагыштырулар.эпитетлар. Рифма,ритм һәм тон. Лирик шигырьләрне уку барышында матурлыкны шагыйрь күзе белән күрергә өйрәнү;
Язучылар иҗат иткән  әкиятләр һәм халык әкиятләренең үзенчәлеген аера белү. Тылысымлы әкиятләрдәге предметлар,образлар;
1-2 сыйныфларда үзләштерелгән төшенчәләрне ныгыту, мисаллар китерә белү. Мәзәкләрне аерып карый белү.

## 3 нче сыйныф (татар төркеме ) татар теленнән 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа  атнага 3 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 105 сәгать. Планлаштырылган контроль эш- 4.(Арадаш аттестация –грамматик биремле контроль диктант)

Программа: “Рус теләндә урта(тулы) гомуми бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы ”(татар балалары өчен) төзүче –авторлары :Ф.Ф.Харисов,Ч.М.Харисова, В.А.Гарипова, 2011

Дәреслек . Татар теле: Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек/ татар балалары өчен. Ф.Ф.Харисов, Ф.М.Хисамова, Ч.М.Харисова.– Казан: ,Татарстан китап нәшрияты

**3 нче сыйныфта татар телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр**

Гамәли максатка ирешү өчен,укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру;
диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү;
төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү;
дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;
татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү

**3 нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр:**

-1-2 нче сыныфларында үткәннәрдән чыгып, сүзләргә фонетик анализ ясау .3 нче сыйныф ахырында укучылар сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсен, күпмәгънәле булуын аерырга

тиешләр. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес билгеләп, аларны сүзтезмә һәм җөмлә төзегәндә куллану.Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.Сүз төзелешен тикшерү күнегүләрен үтәү. Укытучы биргән сүзләрнең тамырын, кушымчаларын табу. Кушма һәм парлы сүзләрнең ясалышын аңлату, язылышын күзәтү.Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен аеру, берлек һәм күплек сандагы исемнәрен аеру, берлек һәм күплек сандагы исемнәрне килеш белән төрләндерү; сыйфатларның сыйфатланмышка, саннарның саналмышка иярү үзенчәлеген ( янәшә тору) аңлау. Саннар янында килгән саналмышның татар телендә берлек санда кулланылуын истә калдыру. Зат һәм сорау алмашлыкларын башка сүз төркемнәреннән аеру, аларны диалогик һәм монологик сөйләмдә куллану. Фигыльләрнең заманнарын билгеләү, хәзерге заман хикәя фигыльләрнең зат-сан белән төрләнешен язма һәм телдән сөйләмдә дөрес куллану. 3 нче сыйныфта өйрәнелгән сүз төркемнәрен кулланып, сүзтезмә һәм җөмләләр төзү.Җөмләнең баш кисәкләрен таба белү. Иярчен кисәкләрдән аергычны билгеләү, аның аерылмышка иярү үзенчәлеген аңлау.

**4 нче сыйныф (татар төркеме), татар теле.**
**(105сәг)**

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

1. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
2. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы ”на (Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011)

**Дәреслек:** Ф.Ф.Харисов “Татар теле”, рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел.

**Максат :**
Укучыларның фикерләү сәләтен үстерү, тел чараларын аралашуның эчтәлегеннән чыгып билгели белү, балаларның ана телендә аралашу күнекмәләрен камилләштерү;
Телнең фонетика, лексика, грамматикасы буенча башлангыч белем алу, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә белү күнекмәләрен булдыру,
Дөрес уку һәм дөрес язу күнекмәләрен булдыру, диалогик сөйләмдә катнашу, гадирәк итеп төзелгән монологик сөйләм оештыру;
Укучыларда ана теленә хөрмәт һәм ярату тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, тел өйрәнүгә кызыксыну уяту.

***Укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:***

- татар графикасы үзенчәлекләрен белү;
- сүзнең мәгънәле кисәкләрен аера белү;
- өйрәнелгән сүз төркемнәрен бер-берсеннән аера һәм аларның үзенчәлекләрен аңлата алу;
- сүзтезмә һәм җөмләләрне бер-берсеннән аеру, җөмләләрнең коммуникатив төрләрен билгели белү;
- җөмләнең баш кисәкләрен, иярчен кисәкләреннән аергычны билгеләү;
- авазларга, сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә, сүз төркемнәренә һәм җөмләләргә өйрәнгән күләмдә кыскача характеристика бирә белү;
- сүзләрнең әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен аңлау;
- авазларны, сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес итеп әйтергә өйрәнү;
- өйрәнелгән җөмлә төрләрен тиешле интонация белән әйтә белү;
- өйләнелгән сүз төркемнәреннән исем һәм фигыльләрне дөрес итеп төрләндерү күнекмәләренә ия булу;
- 35-40 сүздән торган, 9-11 җөмләле текстны дөрес итеп күчереп язу;

- өйрәнелгән орфографик һәм пунктуацион кагыйдәләргә 12-16 сүздән торган сүзлек диктанты, 45-50 сүздән торган контроль диктант язу;
- төрле төрдәге диктант, изложение, сочинениеләр язу;
- тормыш-көнкүрешкә бәйле диалог һәм монологлардан файдалану;
- аваз, сүз, сүзтезмә һәм җөмләләрне дөрес әйтү нормаларын саклау;
- укучыларның сүз байлыгын укуга һәм тормыш-көнкүрешкә бәйле сүзләр хисабына арттыру;
- төрле типтагы сүзлекләр белән эшли белү;
- өйрәнелгән орфографик һәм пунктуацион кагыйдәләрне катлаулы булмаган язма сөйләмдә дөрес куллану;
- көндәлек аралашуга бәйле рәвештә татарча сөйләм этикеты формаларын дөрес куллану.

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр | Контроль эш төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | 26 | -авазлар һәм хәрефләр, сузык һәм тартык авазлар, **ъ** һәм **ь** хәрефләре, алфавит, тамыр һәм кушымча, кушма һәм парлы сүзләр, синоним, антоним, омонимнар, исем, фигыль, сыйфат, алмашлык, сүзтезмә һәм җөмлә, әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре, җөмләнең баш кисәкләре; | Диктант -2 |
| 2 | Морфология | 46 | -исем, исемнәрнең килеш белән төрләнеше, яңгырау һәм саңгырауга беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше, борын авазына беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше; тартым, тартымның берлек сан формасы, тартымның күплек сан формасы;<br>-сыйфат, сыйфат дәрәҗәләре: гади, чагыштыру, артыклык, кимлек;<br>-сан, микъдар саны, тәртип саны;<br>-алмашлык, зат алмашлыклары, зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, тартым алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары;<br>-фигыль, боерык фигыль, хикәя фигыль, хикәя фигыльнең заманнары: хәзерге, үткән, киләчәк;<br>-бәйлекләр, бәйлек сүзләр;<br>-кисәкчә | Диктант -2<br>Сүзлек диктанты – 2<br>Изложение -1<br>Сочинение - 1 |
| 3 | Синтаксис | 26 | -сүзтезмә, җөмлә, җөмләнең баш кисәкләре, ия, хәбәр;<br>-җыйнак һәм җәенке җөмләләр,<br>-җөмләнең иярчен кисәкләре, аергыч;<br>-җөмләнең тиңдәш кисәкләре;<br>-эндәш сүзләр; | Сүзлек диктанты – 2 |
| 4 | Кабатлау | 7 | | Диктант -1 |

**4 нче сыйныф (татар төркеме), әдәби уку (70 сәг.)**

Укыту планында 4 нче сыйныфта укудан атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик план “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы ”на (Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011) нигезләнеп төзелде. Программада 64 сәгать каралган. Мәктәпнең укыту базис планы 35 атнага исәпләнә. Шуңа күрә календарь -тематик план 70 сәгать исәбеннән төзелде.

**Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:**

1. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
2. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы ”на (Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011)
3. **Дәреслек:** Р.Х.Ягъфарова “Уку китабы”, рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014 ел.

**Әдәби укуны укытуның максаты һәм бурычлары:**

- укучыда татарча укуга кызыксыну, омтылыш уяту;
- әдәби уку тәҗрибәсе булдыру;
- үз милләтең белән горурлану, татар теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;
- татар әдипләренең иң яхшы әдәби әсәрләре белән танышу;
- әдәби әсәрләрне дөрес һәм йөгерек, аңлап, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, уку тизлеге нормаларына сыешу;
- татар халык авыз иҗаты әсәрләрен белү, мәкаль һәм әйтемнәрне урынлы куллана белү;
- текстны аңларга, аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә, дөрес һәм матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, тема буенча әңгәмә кора белергә, аралашканда тел чараларын урынлы файдалана белергә өйрәтү;
- әсәрнең темасын һәм төп геройның характерын, эш-гамәлләрен, әсәрдәге вакыйгаларга, геройларга карата үз фикерләрен белдерергә өйрәтү;
- халык әкиятләрен һәм фольклор жанрларын, автор әкиятләрен, хикәя, шигырь, мәзәкләрне һ.б. әдәби жанр буларак кабул итәргә күнектерү;
- төрле милләт вәкилләре арасында дуслык хисе тәрбияләү.

**Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр:**

- шигырьләрне сәнгатьле итеп уку;
- әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләре белән әйтеп бирү;
- кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;

- тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне аера белү;
- әсәрдәге төп геройга мөнәсәбәт белдерү;
- укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белү;
- 2–3 татар классигының исемен;
- 2–3 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, язган әсәрләрен һәм аларның эчтәлеген;
- үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен;
- китапның төрле элементларына карап эчтәлеген билгеләү;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу;
- әсәрләрнең геройларына характеристика бирү, чагыштырулар;
- авторның үз героена мөнәсәбәтен билгеләү;
- яраткан әдәби герое турында сөйли белү;
- дәреслектә дөрес ориентлашу, китап элементларын төгәл билгеләү, авторын, исемен, эчтәлек язылган битне табу, иллюстрацияләр белән эшли белү;
- тематик, монографик әсәрләр җыентыклары төзи белү;
- төрле авторларның 6–8 әсәрен яттан белү;
- мөстәкыйль рәвештә китаплар сайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сүзлекләр белән мөстәкыйль эшләү;
- аңлап, йөгерек уку күнекмәләре булдыру;
- текстның темасын, төп фикерен табу, текстны мәгънәви кисәкләргә бүлү, текстның планын төзү, тулы һәм кыскача эчтәлекне бирә белү;
- фольклор әсәрләрен тану, автор әсәрләре белән уртаклыгын, аермасын билгеләү;
- әсәрдәге геройлар турында үз фикерләрен әйтә белүләренә ирешү, геройларның характерын ачыклау, чагыштыру;
- сайлап алып, әсәрне яки бер өзекне яттан өйрәнү; ныгыту;
- дәреслектә оста ориентлашу;
- әсәрдән өзекләр китереп, аннотацияләр язу;
- уку елында өйрәнелгән әдәби әсәрләрнең исемен, авторын, эчтәлеген;
- 1–2 балалар журналын, аның бүлекләрен;
- теге яки бу авторларның китапларын (бирелгән исемлек буенча, чыгыш әзерләү өчен) мөстәкыйльрәвештә китапханәдәсайлый белү, китап элементлары буенча аның эчтәлеген ачыклау;
- сайланган әсәрләрне мөстәкыйль уку.

| № | Төп темалар | Сәг. |
|---|---|---|
| 1 | Табигать һәм без. | 16 |
| 2 | Озын-озын балачак | 18 |
| 3 | Тәрҗемә әсәрләр | 9 |
| 4 | Шигърият | 9 |
| 5 | Халык авыз иҗаты | 18 |

## 5 нче сыйныф (татар төркеме ) татар теленнән 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 3 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 105 сәгать. Планлаштырылган контроль эш- 4 сәгать.(Арадаш аттестация –грамматик биремле контроль диктант)

Программа: "Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы "(татар балалары өчен) төзүче –авторлары :Ф.Ф.Харисов,Ч.М.Харисова, В.А.Гарипова, 2011

Дәреслек :"Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы (татар балалары өчен)" (/ Ф.ФХарисов, Ч.М.Харисова. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2009

**5 нче сыйныфта татар телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр**

татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, теленә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү;татар теленең барлык бүлекләре буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү;сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү;телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү;туган тел ярдәмендә өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау;татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру;укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.

**5 нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр:**

Сузык һәм тартыкларны классификациясен , алардагы аерманы таный белү;татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү;аваз һәм хәрефләрне аера белү; Алфавитны истә калдыру; сүзләргә фонетик анализ ясау;орфоэпик һәм орфографик сүзлекләрдән файдалану;татар теленең сүзлек составының килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу активлыгы буенча бәяли белү.Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану. Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.Сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш үзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.Өйрәнелгән сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү..Сүз төркемнәренең төрле ысул белән ясалышын белү.Сүтемәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.Гади һәм кушма җөмләләрне аера белү.Җөмләнең әйтү максаты буенча төрен билгели белү.Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табып, аларның кайсы сүз төркемнәре белән белдерелүен күрсәтү

## 5 нче сыйныф (татар төркеме ) татар әдәбиятыннан 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 2сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 70 сәгать.Арадаш аттестация –тест формасында.

Программа: .«Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү оешмаларының татар сыйныфлары өчен татар әдәбиятыннан программа» (Төзүче-авторлар: Ф. Ф. Хәсәнова,Г. М. Сафиуллина, М. Я.Гарифуллина),

Дәреслек 5нче сыйныф өчен Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, М. Я. Гарифуллиналар эшләгән (Казан, Мәгариф — Вакыт, 2014), Татарстанның Мәгариф Һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән .

**5 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан төп бурычлары түбәндәгеләр**

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел формаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку күнекмәләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү.
2. Балаларны гомумән татар әдәбияты, халык авыз иҗаты,татар халкының җыр-музыкасы, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларньщ әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен (яки әдәби әсәрләрдән өзекне) укып үзләштерү, алар турында үз фикерләрен әйтергә өйрәтү.
3. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлату һәм кулланырга өйрәтү.
4. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, милләттәшләребез тормышы турында мәгълүмат бирү.
5. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша укучыларда Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм гомумән кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.Эстетик тәрбия бирү, табигатькә сакчыл, мәрхәмәтле караш уяту.
6. Татар, рус һәм башка халыклар әдәбиятларын чагыштырып карау күнекмәләре булдыру.

**Предмет буенча укучылар үзләштерергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре**

сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау; өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү; әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау; укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;геройларга характеристика бирү;сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу; әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру; укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү; әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку; кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикер белдерү;укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилли белү; татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле те мага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү; эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәклемәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

**5 нче сыйныф, рус төркеме (татар теле)**

5 нче сыйныфта татар теленнән атнага 3 сәгать вакыт бирелә. “Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту” программасында 102 сәгать каралган. Мәктәпнең укыту базис планы 35 атнага исәпләнә. Шуңа күрә календарь -тематик план 105 сәгать исәбеннән төзелде.

**Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:**

1.Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
2.“Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту”. Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Казан “Татамультфильм” – 2014
3.Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар) Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, 2014
4. “ Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче балалар өчен) Р.З.Хәйдәрова.- Казан: татармультфильм, 2014 ) буенча укыту планлаштырыла.

**Танып белү максатының эчтәлеге:**

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып торган татар халкы мәдәнияте, гореф-гадәтләре, тарихи үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында хәбәрдар булу зарур. Шуңа күрә программа материалын өйрәнү барышында укучыларның Татарстан Республикасында яшәүче милләтләр, Татарстанның дәүләт символлпры, республиканың территориясе, географик урыны; башкалабыз Казанның тарихи үткәне, бүгенге йөзе; татар сәнгатенең төрле тармаклары, күренекле шәхесләр турында билгеле бер мәгълүмат алуы саксат итеп куела.

**Үстерү максатының эчтәлеге:**

Шәхеснең белемле булуы тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында **үстерү максатларын** даими күзаллап эшләү – укытуның гамәли яктан уңышлылыгының алшарты.

Балаларның психик яктан камилләшүен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә игътибар бирү таләп итеlә:

- Фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп – нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерләү;
- Хәтерне (ихтыярый, ихтиярсыз), игътибарлылыкны үстерү;
- Аралаша белү сәләтен үстерү;
- Ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

**Тәрбияви максатның эчтәлеге:**

Тәрбиянең нәтиҗәлелеге, беренче чиратта, укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләре исәпкә алына. Татар теле грамматикасын өйрәнү барышында әхлакый проблемаларны чагылдырган текстлар белән эшләү, ул текстларны лексик-грамматик яктан анализлау белән генә чикләнмичә, текстта күтәрелгән проблема буенча укучыларның үзара фикерләшә, аралаша белүләре оештырыла.

**Белем бирү максатының эчтәлеге**

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр җыелмасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык югарылыкка җитүе зарур. Ягъни укучы, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатыннан мөстәкыйль кулланырлык итеп өйрәнергә тиеш. Шул вакытта гына татар телен аралашу чарасы буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Дәреслекнең тематик эчтәлеге**

5 нче сыйныфта татар сөйләменә өйрәтү максатларында барлыгы 5 тема буенча лексик материал сайланды.

Тематик эчтәлек:

**1.** Без мәктәптә (27 **сәг.)**
**2.** Мин — өйдә булышчы (37 **сәг.)**
**3.** Дуслар белән күңелле (23**сәг.)**
**4.** Дүрт аяклы дусларыбыз (8 **сәг.)**
**5.** Без спорт яратабыз (10 **сәг.)**

**Контроль эш төрләре:**

— Сочинение – 2
— Сүзлек диктанты – 4
— Контроль эш – 3

**Үзләштерелергә тиешле грамматик материал.**

1. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.
2. Тартым һәм килеш белән төрләнгән исемнәрнең берлек һәм күплек сандагы кушымчаларын аера белү.
3. Тамыр, кушма, парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларның сөйләмдә кулланылуын кабатлау.
4. Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе.
5. Сыйфат дәрәжәләре белән таныштыру, аларны сөйләмдә куллану.
6. Микъдар, тәртип, җыю саннарын аера белү.
7. *Мин, син, ул* зат алмашлыкларын иялек, төшем, урын-вакыт килешләрендә сөйләмдә куллана белү.
8. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат- сан белән төрләнешен сөйләмдә куллану.
9. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен сөйләмдә куллану.
10. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.
11. Боерык фигыльнен зат-сан белән төрләнешен сөйләмдә куллану.
12. Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану.
13. Фигыльнен инфинитив формасын модаль сүзләр *{кирәк, кирәкми, ярый, ярамый*) белән сөйләмдә куллану.
14. *Эшләргә телим* төзелмәсен сөйләмдә куллану.
15. *Өчен, шикелле* бәйлекләрен сөйләмдә куллану.
16. Минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, минем фикеремчә *кереш сүзләрен сөйләмдә куллану.*

**5 нче сыйныф, рус төркеме (татар әдәбияты)**
**70 сәг.**

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

4. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
5. Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре (V-VII сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан авторлык программасы
   Төзүче-авторлары: Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов, Л.К.Хисмәтова, Э.Х.Гыйзәтуллина, Г.Г.Мулласалихова – Казан: 2014

**Дәреслек:** Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанов,Л.К.Хисмәтова “Татар әдәбияты”, Казан, “Мәгариф – Вакыт”, 2014 ел.

Татар әдәбиятын өйрәнүнең **максаты** – туган халкының һәм җирле халыкның телен, мәдәниятен, әдәбиятын яхшы белгән, һәрьяктан камил, милли горурлык хисләре үскән шәхес (гражданин) тәрбияләү.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен, түбәндәге **бурычлар** билгеләнде:

− Татарстан төбәгендә яшәп, җирле халык белән аралашкан укучыларны төбәкнең әдәби-мәдәни байлыгы белән якыннан таныштыру;

− татар әдәбияты турындагы мәгълүматларны төрле халык фольклоры, әдәбияты, мәдәнияте, милли образлары белән чагыштырма-типологик аспектта бирү;

− татар халык авыз иҗаты турында тулы күзаллау булдыру, аны баланың үз туган халкының рухи җәүһәрләре белән чагыштырырга күнектерү;

− татар әдипләре, мәдәният әһелләре турында күзаллау булдыру, аларны танырга, аңларга, башка халык сүз сәнгатен үстерүчеләр белән чагыштырма планда бәяләргә өйрәтү;

− татар, рус, Россиядә яшәүче башка халыклар, бөтендөнья әдәбияты белеме казанышларының уртак нигезен аңлау, аларны үстерү һәм киңәйтү.

**5 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

– әдәби әсәрләрне, сүзләрен дөрес әйтеп, йөгерек уку;

– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;

– әдәби – теоретик төшенчәләрне рус әдәбият белеме белән тәңгәлләштерү;

– татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;

– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;

– 8 − 10 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;

– 3 − 4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗатын турында мәгълүматлы булу;

– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;

– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

– 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән истә калдыру;

– мәкаль белән әйтем, фантастика белән әкият арасындагы аерманы белү;

– төрле авторларның 2 − 3 шигырен яттан сөйли белү;

– сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, кирәкле материалны таба белү;

– төрле темаларга проект эше яклау;

– әдәби әсәргә, тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү.

**Курс темаларының эчтәлеге**

Борын-борын заманда...

Әкият яздым – укыгыз...

Хыял канатларында.

Белем баскычлары.

Балачак – хәтердә мәңге калачак...

Ватаным өчен.

Кояшлы ил – бәхет иле.

Кеше − табигать баласы.

Эш беткәч көләргә ярый.

**Сәгатьләр бүленеше:**

Тест – 8;

Проект – 4;

Әсәрләрне өйрәнү – 58.

## 6 нчы сыйныф (рус төркеме ) татар әдәбиятыннан 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 1сәгатьтән исәплнгән. Уку елына барысы 35 сәгать. Арадаш аттестация –тест формасында.

Программа: “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013

Дәреслек. Татар теле.” 6 нче сыйныф өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) Р.З.Хәйдәрова.- Казан: Мәгариф, 2008.

**6 нчы сыйныфта татар әдәбиятыннан төп бурычлары түбәндәгеләр**

Рус телендә сөйләшүче балалар өчен әдәби уку дәресләре татар язучыларының иң матур әсәрләре белән танышу, аларны дөрес интонация белән, басымнарны урынлы куеп уку, аңлау, истә калдыру, аерым гыйбарәләрне, сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләләрне сөйләмгә кертеп җибәрүгә юнәлдерелә. Әдәби текст баланы матур җөмләләр төзеп сөйләргә, татарча аралашуга этәрә.

**Предмет буенча укучылар үзләштерергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре**

1.Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга өйрәтү.
2. Сәнгатьле укырга әзерлек кагыйдәләрен хәтергә сеңдерү. Эчтәлеккә туры килгән картинаны күз алдьна китерү, шигырь яңгырашын ишетә белү.
3. Йөгерек, аңлы, дөрес, сәнгатьле уку. Әдәби тел нормаларын истә тотып, теләсә нинди жанрда язылган әсәрне үзлектән аңлап укый белү.
4. Укылган әсәрләрдән төп фикерне укучының аерып күрсәтә алуы, үз сүзләре белән төп фикерне әйтә белүе, текстньң төп фикерен билгеләп, әлешәләргә, кисәкләргә аеру.
5. Текстны үзлектән төзелгән планга нигезләнеп, иллюстрациягә таянып, кыска һәм төгәл итеп сөйли белүләре. Аерым темага хикәя төзү ечен материал табу.
6. Әдәби әсәрдәге геройларга бәя бирергә өйрәтү.
7. Тексттагы сүзләрнең мәгънә төсмерләрен аера белү, аларны сөйләмгә кертеп җибәрү. Әсәрдә аларны табу, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләренә игътибар итү, мәгънәләрен аңлап калу.
8. Текстны үзлектән төзелгән планга нигезләнеп, иллюстрациягә таяньп, кыска һәм төгәл итеп сөйли белүләре. Аерым темага хикәя төзү өчен материал табу.
9. Иҗади хикәяләр төзү: кайсы да булса бер герой исеменнән, ягъни затын үзгәртеп сөйләү, геройның язмышы турында хикәяне дәвам итү, тормыштагы вакыйгалар турында хикәя төзү, күзәтү элементларын кертеп, тасвирлауны үзгәртеп сөйләү күнекмәләре булдыру.
10. Язучы биографиясен билгеле бер эзлеклелектә сөйләү күнекмәләре булдыру.

**6 нчы сыйныф, татар төркеме (татар теле)**

Менделеев шәһәре муниципаль бюджет гомуми урта белем бирү учреждениесе “Гимназия №1”нең 2014-2015 нче уку елына уку-укыту планы нигезендә татар теле дәресләрен атнага 3 сәгать исәбеннән, елга 105 сәгать укыту каралган.

**Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:**

6. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
7. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар”(Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011)

**Дәреслек:** Н.В.Максимов “Татар теле”, рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 6нчы сыйныфы өчен дәреслек. Казан, Мәгариф, 2010 ел.

**ТӨП МАКСАТ** –Рус мәктәбендә татар теленә өйрәткәндә укучыларда лингвистик (тел), коммуникатив (аралашу), милли мәдәният өлкәсенә караган культурологик (мәдәниятлылык) компетенцияләр булдыру.

**БУРЫЧЛАР:**

- татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, теленә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү;
- татар теленең барлык бүлекләре буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү;
- сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү;
- телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү;
- туган тел ярдәмендә өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау;
- татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру;
- укучыларныдаимирәвештә татар миллимәдәниятемирасынатарту;
- татар теле дәресләрендә белем бирү белән бергә тәрбияви бурычны да онытмау. Телебезнең тәрбияви мөмкинлекләрен ачуда укуга карата кызыксыну уяту. Изложение һәм сочинениеләрне дә тәрбияви бурычны күз уңында тотып яздыру.
- укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү. Аралашканда, фикерләрне ачык, аңлаешлы, эзлекле, стилистик яктан дөрес, төгәл итеп белдерү. Укучыларда ана телендә дөрес, матур итеп сөйләү һәм язу күнекмәләре тәрбияләү;
- дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

## Укучының белем дәрәҗәсенә таләпләр

**Фонетика буенча**:

-сузык һәм тартыкларны классификациясен , алардагы аерманы таный белү;
- татар телендә иҗек калыплары, сүзләрне дөрес басым белән әйтү;
- аваз һәм хәрефләрне аера белү; Алфавитны истә калдыру;
- сүзләргә фонетик анализ ясау;
- орфоэпик һәм орфографик сүзлекләрдән файдалану;

**Лексикология буенча:**

- татар теленң сүзлек составын килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм кулланылу активлыгы буенча бәяли белү.
- Сүзләрне һәм фразеологизмнарны урынлы куллану, аларның мәгънәләренә аңлатма бирә белү. Синоним, омоним, антоним сүзләрне дөрес куллану.
- Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.

**Сүз төзелеше һәм сүз ясалышы буенча:**

- сүзләрнең мәгънәле кисәкләренә аңлатма бирә белү. Тамырдаш үзләр табу. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
- Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

**Морфология буенча:**

- өйрәнелгәнсүз төркемнәрен лексик-грамматикмәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера һәм аларны таный белү. Морфологик анализ ясау.
- өйрәнелгәнсүз төркемнәре белән җөмләләр һәм текстлар төзү. Суз төркемнәренең төрле ысул белән ясалышын белү.

**Синтаксис буенча:**

- сүзтемәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
- Гади һәм кушма җөмләләрне аера белү.
- Җөмләнең әйтү максаты буенча төрен билгели белү.
- Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табып, аларның кайсы сүз төркемнәре белән белдерелүен күрсәтү

**Эш кәгазьләре буенча:**

- төрле эш кәгазьләрен ( хат, белдерү, гариза, ышаныч кәгазе һ.б.) яза белү

**Сөйләм эшчәнлеге буенча:**

1. Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
2. Укыган яки тыңлаган текстның эчтәлеген сөйләү, планын төзү.
3. Бирелгән план буенча сочинение (хикәя) язу.
4. Татарчадан русчага яки русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре эшләү.

**Контроль эш төрләре**

Изложение -5
Сүзлек диктанты - 1
Диктант -6
Сочинение -4

**6 нчы сыйныф, татар төркеме (әдәбият)**

Менделеев шәһәре муниципаль бюджет гомуми урта белем бирү учреждениесе “Гимназия №1”нең 2014- 2015 нче уку елына укыту планы нигезендә татар әдәбияты дәресләренең саны (барлыгы) **35**, атнага **1**тапкыр үткәрелә. Программада текстны уку, сөйләм үстерүгә, дәрестән тыш укуга 68 сәгать каралган, шуңа күрә тематик план темаларга бирелгән сәгатьләр санын кыскарту нигезендә үзгәртелде.

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

1. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
2. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар”(Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011)

**Дәреслек**: “Татар әдәбияты”(Ф.Г.Галимуллин,Ф.К Мифтиева, И.Г. Гыйләҗев. татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 6 нчы сыйныфы өчен - Казан: Мәгариф, 2010)

**Максат:**

- Татар әдәбияты текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү; төп әдәби-тарихи мәгълүматлардан, әдәби барышны тәэмин итүче төп әдипләр иҗаты турында хәбәрдар булу һәм гомум әдәби - теоретик төшенчәләрне татар әдәбиятына мөнәсәбәтле куллана белү;
- Татар әдәбияты тарихының төп фактларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау күнекмәләре формалаштыру; әсәрләрдәге конкрет – тарихи һәм гомумкешелек өчен мөһим эчтәлекне күрә белү; телдән һәм язма чыгышларды әдәби тел байлыгыннан дөрес файдалану күнекмәләре булдыру;

- Әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны; китап укучы культурасын һәм автор позициясен аңлауны; сәнгать төрләре белән берлектә әдәбиятнең сүз сәнгате буларак үзенчәлеге турында карашны; матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру; укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
- Татар әдәбияты, мәдәнияте белән кызыксыну, дөньяга гуманлы караш,татар халкының мәдәни кыйммәтләренә хөрмәт булдыру, ягъни рухи дөньясы бай һәм башка мәдәниятләрне хөрмәт белән кабул итүче шәхес тәрбияләү;

**Бурычлар:**

- Әдәби әсәрләрне бала күңеленә сеңдерү, аларның мәгънәсен, нәфислеген төшендерү;
- Укучыларда күркәм сыйфатлар тәрбияләргә булышу;
- Әсәрләрне күбрәк укырга теләк уяту һәм тәрбияләү;
- балаларны татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү;
- укучыларда Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, кешеләргә һәм әйләнә-тирәгә гуманлы караш тәрбияләү;
- кешенең табигатькә мәрхәмәтле булуына ирешү;
- матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку күнекмәләре формалаштыру;

## Укучының белем дәрәҗәсенә таләпләр

1. Өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген белү; классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын истә калдыру;
2. Әдәби текстны кабул итү һәм анализлау, укыган буенча план төзү; геройларга характеристика бирү; әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру, автор позициясен ачыклау;
3. Укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку; җырлар һәм аларның төрләрен аера белү;
4. Хикәя,фантастик хикәяне аера белү; шигырь һәм поэманың үзенчәлекләрен белү; уңай герой,лирик герой төшенчәләрен аера белү;
5. Әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү; милли орнаментларны аера белү.
6. Татар әдәбиятының күренекле язучылары һәм шагыйрьләре, аларның әсәрләре турында мәгълүмат булдыру; төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
7. Шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү; әсәрләрне анализлау; план төзү һәм әсәрләр турында кыскача бәяләмә (отзыв) язу; татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып бәяләү, үз фикерен әйтә белү.

## 7 нче сыйныф, рус төркеме (татар теле)

Менделеев шәһәре муниципаль бюджет гомуми урта белем бирү учреждениесе “Гимназия №1”нең 2014- 2015 нче уку елына укыту планы нигезендә татар теле дәресләренең саны (барлыгы) **105**, атнага **3**тапкыр үткәрелә.

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

8. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
9. “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы ” (Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова, Казан, 2013)

3.“ Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбе 7 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) Р.З.Хәйдәрова.-Казан: татар китап нәшрияты, 2008)

Татар теленә өйрәтүнең **ТӨП МАКСАТЫ – гамәли максат**: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү. **Гомуми белем бирү максаты** укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. **Тәрбияви максат** балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

**БУРЫЧЛАР**:
1. Татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.
2. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә белем бирү.
3. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнкмәләрен камилләштерү. Көндәлек тормышта татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.
5. Туган тел аша өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.
6. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.
7. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.
8. Татар теле дәресләрендә, белем бирү белән бергә, тәрбияви бурычны да онытмаска кирәк. Изложение, сочинениеләр дә тәрбияви бурычны күз уңында тотып яздырылырга тиеш.
9. Программа укучыларның логик фикерләү дәрәҗәсен үстерү бурычын да куя. Балалар, ана телендә аралашканда, фикерләрен ачык, аңлаешлы, эзлекле, стилистик яктан дөрес, төгәл итеп адресатка җиткерергә тиеш. Бу бер үк вакытта сөйләм теленә дә, язма телгә карый.

**Программаның эчтәлеге**

| № | Бүлекләр, темалар | Сәгать саны | Контроль эшләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Мәктәп тормышы. | 18 | Тест -1 |
| 2. | Мин һәм минем яшьтәшләрем. | 12 | Директор контроль эше -1<br>Сочинение -1 |
| 3. | Ял итү. | 13 | Сүзлек диктанты – 1<br>Контроль эш -1 |
| 4. | Өлкәннәр һәм без. | 12 | Сүзлек диктанты -1<br>Сочинение -1<br>Тест - 1 |
| 5. | Дүрт аяклы дусларыбыз | 9 | Сүзлек диктанты -1 |
| 6. | Әдәбият-сәнгать дөньясында. | 15 | Директор контроль эше -1 |
| 7 | Туган җирем Татарстан. | 14 | Сүзлек диктанты -1<br>Изложение - 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | Сфетофор - минем дустым. | 12 | Арадаш аттестация |
| | Барлыгы: | 105 | Сүзлек диктанты– 4<br>Контроль эш -4<br>Сочинение -2<br>Изложение – 1<br>Тест - 2 |

**Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- татар теленең төп берәмлекләрен һәм аларның билгеләренең белү ;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын ,грамматик төзелешен үзләштерү;
- грамматик үзенчәлекләренә карап, сүз төркемнәрен аера белү;
- җөмлә төрләрен аеру, алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәнү ;
- текст төзелешен, текстның тел үзенчәлекләрен билгеләү;
- сөйләм стиле, фәнни ,публицистик, рәсми эш, матур әдәбият стильләрен аера белү.

**7 нче сыйныф, рус төркеме (әдәбият)**

Менделеев шәһәре муниципаль бюджет гомуми урта белем бирү учреждениесе "Гимназия №1"нең 2014- 2015 нче уку елына укыту планы нигезендә татар әдәбияты дәресләренең саны (барлыгы) **35**, атнага **1**тапкыр үткәрелә.

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

1. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
2. "Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы " (Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова, Казан, 2013)

" Татар теле: рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәбе 7 нче сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) Р.З.Хәйдәрова.- Казан: татар китап нәшрияты, 2008. )

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле һәм әдәбияты буенча системалы фәнни белем бирү, аларны ирекле аралашырга өйрәтү, татар дөньясы турында күп кырлы мәгълүмат җиткерү **ТӨП МАКСАТ** итеп билгеләнелә.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге **БУРЫЧЛАР** үтәлергә тиеш:
-татар сөйләмен тыңлап аңларга өйрәтү;
-татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
-программада күрсәтелгән темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
-карап чыгу,танышу,өйрәнү,эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
-фразеологик берәмлекләрнең,мәкальләрнең рус эквивалентларын табарга һәм чагыштырырга өйрәтү;
-татар телендәге сөйләмне фонетик,лексик,грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;
-татар халкының фән,мәгариф,сәнгать,мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
-халыкларның үзара аңлашып яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

**Укучының белем дәрәҗәсенә таләпләр**

1. ТЫҢЛАП АҢЛАУ. төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү; сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап,эчтәлегебуенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап-аңлап эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралаша белү; сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

2. ДИАЛОГИК СӨЙЛӘМ Сорау, җавап, килеш(мә)ү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып әңгәмә кору, сөйләшә белү; аралашуда катнаша, аны туктата һәм аны яңадан башлый белү; парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү; Терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү; Татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынны файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

3. МОНОЛОГИК СӨЙЛӘМ Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү; конкрет ситуациягә үз карашыңны, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү; монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү; өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү; өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

4. УКУ Программада тәкъдим ителгән текстларны татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку; текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү; таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү; таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

**Программаның эчтәлеге**

Мәктәп тормышы.
Мин һәм минем яшьтәшләрем.
Ял итү.
Өлкәннәр һәм без.
Дүрт аяклы дусларыбыз
Әдәбият-сәнгать дөньясында.
Туган җирем Татарстан.
Сфетофор - минем дустым.

## 8нче сыйныф (татар төркеме), татар теле

Программа һәм Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе "Гимназия №1"нең 2014-2015 уку елына уку планы нигезендә 8 нче сыйныфта татар телен укыту атнага - 3, уку елына 105 сәгать каралган.

**Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:**

10. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
11. "Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар "ы (Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2011)

**Дәреслек:** "Рус телендә урта гомуми белем белем бирүче мәктәпнең 8 нче сыйныфы өчен дәреслек" (татар балалары өчен, Татарстан Республикасы, Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән, авторлары: Р.А. Асылгәрәва, Р.А. Юсупов, Казан, "Татарстан китап нәшрияте", 2011 ел.)

Рус мәктәбендә татар теленә өйрәтүнең **максаты** – укучыларда лингвистик (тел), аралашу (коммуникатив), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру.

Рус мәктәбендә ана теле буларак татар теле укытуның **төп бурычлары** түбәндәгеләр:

1. Татар телен өйрәнүгә карата кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

2. Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү.

3. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү.

4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теле мөмкинлекләреннән тулысынча файдалана белергә өйрәтү.

5. Туган тел ярдәмендә өзлексез белем һәм тәҗрибә туплау.

6. Татар телен башка фәннәр буенча белем алу чарасы буларак кулланырга өйрәтү күнекмәләре булдыру.

7. Укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту.

8. Телебезнең тәрбияви мөмкинлекләрен истә тотып, укуга кызыксыну уяту

9. Укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү.

10. Дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү.

**8 нче сыйныфта татар теленнән уку-укыту курсы программасының эчтәлеге**

| Тәртип саны | Бүлекләр һәм темалар | Барлык сәгатьләр саны | Контроль эш төрләре: |
|---|---|---|---|
| 1. | 5-7нче сыйныфларда үткәннәрне кабатлау | 5 | Диктант – 1 |
| 2. | Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат. | 2 | |
| 3. | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Сүзтезмә | 10 | Диктант – 1<br>Изложение -1 |
| 4. | Җөмлә кисәкләре | 34 | Диктант – 3<br>Сочинение – 2<br>Изложение - 1 |
| 5. | Җөмләнең модаль кисәкләре | 5 | Сочинение –1 |
| 6. | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | 6 | Изложение - 1 |
| 7. | Җөмләдә сүз тәртибе | 6 | Сочинение –1 |
| 8. | Гади җөмлә төрләре | 12 | Изложение – 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Диктант –1 |
| 9. | Ике составлы һәм бер составлы җөмлә турында гомуми төшенчә | 4 | Изложение – 1 |
| 10. | Тулы һәм ким җөмләләр | 4 | Сочинение –1 |
| 11. | Раслау һәм инкяр җөмләләр | 2 | |
| 12. | Туры һәм кыек сөйләм | 9 | Диктант – 1<br>Сочинение – 1 |
| 13. | Гади җөмлә синтаксисын гомумиләштереп кабатлау | 6 | |
| | Барлыгы: | 105 | Диктант – 7<br>Сочинение – 6<br>Изложение - 5 |

**8 нче сыйныфта укучыларның татар теленнән белем, осталык, күнекмәләренә төп таләпләр**

**Фонетика буенча**:
1. Татар телендәге сузык һәм тартык авазлар классификациясен, алардагы үзгәрешләрне белү.
2. Татар телендә иҗек калыпларын белү, сүзләрне дөрес басым белән әйтү. Җөмләләрдә логик басымны дөрес билгеләү, тиешле интонация белән әйтү.
3. Сүзләргә фонетик анализ ясау.
5. Аваз һәм хәреф төшенчәләрен аеру. Алфавитны белү.

**Лексикология һәм фразеология буенча:**
1. Татар теленең сүзлек составын килеп чыгуы, кулланылу өлкәсе һәм активлыгы буенча бәяли белү.
2. Төрле типтагы сүзлеләр белән эшләү.

**Сүз төзелеше һәм ясалышы буенча:**
1. Сүздәрнең мәгънәле кисәкләрен билгели белү. Тамыр һәм кушымчаларга аңлатма бирү. Сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерү.
2.Татар телендә сүзләрнең ясалыш ысулларын белү.

**Морфология буенча:**
1. Сүз төркемнәрен лексик-грамматик мәгънәсе, морфологик һәм синтаксик билгеләре буенча аера, таный белү. Морфологик анализ ясау.
2. Өйрәнелгән сүз төркемнәре белән җөмләләр, текстлар төзү. Сүз төркемнәренең төрле ысуллар белән ясалышын белү.
3. Сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау.

**Синтаксис һәм пунктуация буенча:**
1. Сүзтезмәләргә, гади җөмләләргә синтаксик анализ ясый белү..
2. Сүзтезмәне җөмләдән аера белү. Сүз төркеме белән җөмлә кисәген дөрес билгеләү.
3. Аерымланган җөмлә кисәкләре, эндәш һәм кереш сүзләр керпгән җөмләләр төзү.
5. Туры һәм кыек сөйләмне дөрес куллану, алар кергән җөмләләр төзү
6.Гади җөмлә төрләрен белү.
7. Җөмләдә сүз тәртибен билгеләү.

**Сөйләм эшчәнлеге буенча.**
1.Укучыларның, үз тәҗрибәләреннән чыгып, диалогик һәм монологик сөйләм оештыра белүе.
2. Укыган яки тыңлаган текстның эчтәлеген сөйләү, плпнын төзү.
3.Бирелгән план буенча сочинение язу.

4. Караган фильм, спектакль буенча хикәя төзү.
5. Программа буенча укылган китапның эчтәлеген сөйләү яки язу, үз фикереңне белдерү.
6. Әдәби геройларны сурәтләп бирү.
7. Эш кәгазьләреннән гариза, белдерү, ышаныч кәгазе һ.б. язу.
8. Сочинение элементлары булган изложение язу
10. Татарчадан русчага яки русчадан татарчага тәрҗемә итү, күнегүләрне эшләү.

**Татар әдәбияты, 8нче сыйныф, татар төркеме.**

1. Менделеев шәһәре муниципаль бюджет гомуми урта белем бирү учреждениесе “Гимназия №1”нең 2014- 2015 нче уку елына укыту планы нигезендә татар әдәбияты дәресләренең саны (барлыгы) 35, атнага 1тапкыр үткәрелә. Программада текстны уку, сөйләм үстерүгә, дәрестән тыш укуга 68 сәгать каралган, шуңа күрә тематик план темаларга бирелгән сәгатьләр санын кыскарту нигезендә үзгәртелде.
2. Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:
3. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
4. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар ”ы (Ч.М. Харисова, К.С. Фәхуллова, Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2011)
5. Дәреслек: Дәреслек: З.Н.Хәбибуллин, Х.Г.Фәрдиева, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов ”Татар әдәбияты” 8 нче сыйныф, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011нче ел.

**Максат һәм бурычлар.**

6. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү.
7. Балаларны гомумән татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү.
8. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, чит илләрдәге милләттәшләребез тормышы турында мәгълүматлар бирү.
9. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша яшьүсмерләрдә Ватанга, халыкка, туган илгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек , шәфкатьлелек тәрбияләү. Шулай ук хезмәт тәрбиясе һәм эстетик тәрбия бирү.

**8нче класс укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр.**

Татар халык авыз иҗаты жанрларыннан:

- әкиятләр, аларның төрләрен, геройларның төп сыйфатларын аера белү;
- язучылар язган әкиятләрнең үзенчәлекләре;
- дөнья халыклары әкиятләре;
- мәкальләр һәм табышмаклар. Укучыларның тапкырлыгын, зирәклеген билгеләүдә аларның роле;
- җырлар һәм аларның төрләрен аера белү;
- бәетләр, аларда сурәтләнгән вакыйгалар.

*Әдәбият теориясеннән;*

- хикәя, фантастик хикәя, очерк, повесть, нәсерне аера белү;
- автобиографик повесть;
- шигырь һәм поеманың үзенчәлекләрен белү;
- комедия жанры турында аңлатып бирү;

- әдәби әсәрнең сюжетын тотып ала белү;
- уңай герой, лирик герой төшенчәләрен аера белү;
- әдәби әсәрләрдән сурәтләү чараларын таба белү.

*Татар мәдәниятеннән:*

- татар халкының гаилә-көнкүреш, гореф-гадәт һәм йолаларын аңлата белү;
- милли орнаментларны аера белү;
- әдәбиятка бәйле рәвештә *балет, опера, сынчы* кебек терминнарны аңлатып бирә белү сорала.

Сөйләм эшчәнлегенә:

- текстның исеме, андагы таныш сүзләр ярдәмендә укучыларның эчтәлекне аңлаулары;
- укылган текст турында әңгәмәдә катнаша алу, сөйләмдә гади һәм җәенке җөмләләрдән файдалана алу;
- өйрәнелгән язучылар турында сөйләп бирү;
- укылган текстның эчтәлеген сөйли һәм нәтиҗә ясый белү, аңа үз мөнәсәбәтеңне белдерә алу;
- тәкъдим ителгән ситуация, тема яки рәсем турында 12-14 җөмләдән торган текст белән сөйли белү;
- уку һәм сөйләм барышында орфоэпик нормаларны саклау;
- балалар өчен басылган вакытлы матбугат материалларын уку һәм файдалана белү.

**8 сыйныфта укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы (15)**

*Татар әдипләренең әсәрләре:*

- Г.Тукай “Пар ат”;
- Г. Ибраһимов “Алмачуар”;
- Ш. Камал “Буранда”;
- С. Хәким “Җырларымда телим”;
- Ф. Хөсни “Сөйләнмәгән хикәя”;
- Ш. Маннур “Муса”(өзек);
- Г. Афзал “Юл газабы”, “Йөз кабат”;
- М. Мәһдиев “Кеше китә, җыры кала” (өзек);
- Ф. Садриев “Бәхетсезләр бәхете” (өзек);
- М. Әгъләм “Каеннар илендә”;
- Р. Харис “Ике гөл”
- Т. Миңнуллин “Моңлы бер җыр”(өзек).
- *Биографик белешмәләр*: Г. Афзал, Ф. Садриев, М. Әгъләмов, Т. Миңнуллин (бер әсәр буларак исәпләнә).
- *Рус язучыларының тәрҗемә әсәрләре*: А. Куприн “Олеся”(өзек).

## 9 нчы сыйныф (рус төркеме ) татар теленнән 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 2 сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 68 сәгать. Планлаштырылган контроль эш- 5 сәгать.(Арадаш аттестация –контроль эш)

Программа“Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013

Дәреслек. ” Р.З.Хәйдәрова Р.Л.Малафеева,З.М. Шаһгалиева, Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 9 нчы сыйныфы өчен (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) , Казан, Мәгариф, 2008 ел

**9 нчы сыйныфта татар телен укытуның төп бурычлары түбәндәгеләр**

-лексик-грамматик белемнәрне системалаштыру;
-татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен үстерү;

-программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;

-татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзи белүгә ирешү;

-телдән белдерелгән фикерләрне язмача оештыруны камилләштерү;

**9 нчы сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр:**

1.Татар теленең төп фонетик үзенчәлекләрен, татар теленә генә хас булган фонемаларның дөрес әйтелешен гамәли үзләштерү
2.Татар телендә сүз басымын дөрес куя һәм иҗек чигендәге фонетик үзгәрешләрне истә тотып сөйли белү
3. Актив үзләштерелгән лексик берәмлекләрне дөрес язу
4. Алынма сүзләрне, антоним, синоним, омонимнарны сөйләмдә урынлы куллану
5. Гади һәм кушма җөмләне аера белү
6. Теркәгечле һәм теркәгечсез кушма җөмләләрне, иярченле кушма җөмләләрнең синтетик һәм аналитик төрләрен аера белү һәм рус теленә тәрҗемә итү үзенчәлекләрен гамәли үзләштерү
7. Язма эшләрне грамоталы башкара белү
8. Фразеологик берәмлекләрне кулланып,җөмлә төзү күнекмәләрен ныгыту
9. Текст төзелеше турында төшенчә бирү

## 9 нчы сыйныф (рус төркеме ) татар әдәбиятыннан 2014-2015 уку елы эш программасына аннотация

Программа атнага 1сәгатьтән исәпләнгән. Уку елына барысы 34 сәгать. Арадаш аттестация –тест формасында.

Программа: "Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы" Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013

Дәреслек. .Р.З.Хәйдәрова Р.Л.Малафеева,З.М. Шаһгалиева, Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) , Казан, Мәгариф, 2008 ел

**9 нчы сыйныфта татар әдәбиятыннан төп бурычлары түбәндәгеләр**

-лексик-грамматик белемнәрне системалаштыру;

-татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен үстерү;

-программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;

-татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзи белүгә ирешү;

-телдән белдерелгән фикерләрне язмача оештыруны камилләштерү;

**Предмет буенча укучылар үзләштерергә тиешле белем осталыгы һәм күнекмәләре**

1.Җанлы сөйләмнең төп фикерен билгели, мөһим мәгълүматны сайлый белү күнекмәләрен ныгыту;
2. Үзләштерелгән мәгълүмат белән яңа тыңлаганын чагыштыра һәм бәяли белергә өйрәтү.
3. Аралашканда, орфоэпик, лексик-грамматик нормаларны саклап, сораулар бирә һәм җавап кайтара алу осталыгын камилләштерү.
4. Сөйләм яңалыгын дөрес җиткерүгә, үз фикереңне дәлилли белергә ирешү (репликалар саны 12 шәрдән ким булмаска тиеш).

5.Төрле җөмлә калыпларын кулланып, вакыйгалар, фактлар турында хәбәр итә, үз мөнәсәбәтләрен белдерә, сөйләмне эзлекле һәм аңлаешлы итеп оештыра белү (җөмләләр саны 14тән ким булмаска тиеш)
6.Тексттан кирәкле мәгълүматны таба алу һәм аның эчтәлеген телдән яки язмача яктырта белү, текст белән мөстәкыйль эшләү һәм аны анализлау күнекмәләренә ия булу. Татар һәм рус әдәбиятындагы әсәрләрне чагыштырып, үз фикереңне әйтә белү.
Өйрәнелгән темага сочинение, текстка аннотация язу; язма формада аралашу тәгъбирләрен үзләштерү.
7.Текстларны русчадан татарчага язмача тәрҗемә итә алу.
.

**10 нчы сыйныф, рус төркеме (татар теле)**

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013
буенча 10 нчы сыйныфта 102 сәгать каралган. Гимназиянең еллык календарь укыту графигы буенча 10 нчы сыйныфларда 35 атна булу сәбәпле, эш программасы белем бирү учреждениесенең 2014-2015нче елга гамәлдәге планы буенча атнага 1 сәгать исәбеннән , ягъни татар теленнән 35, әдәбияттан 70 сәгатькә төзелә. Шул сәбәпле, эш программасында, барлык өйрәнелә торган темалар саклануп, сәгатьләр санына үзгәрешләр кертелде. Бу үзгәрешләр программаның эчтәлегендә күрсәтелә. 10 нчы сыйныф өчен әзерләнгән эш программасының эчтәлеген мәктәптә үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр тәшкил итә.

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

12. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
13. “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013
14. З.Хәйдәрова. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) , Казан, Мәгариф, 2009 ел.

Фәнне өйрәтүнең **төп максаты – гамәли максат**: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү**. Гомуми белем бирү максаты** укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. **Тәрбияви максат** балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

**Бурычлар:**

- лексик-грамматик белемнәрне системалаштыру;
- татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен үстерү;
- программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
- татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзи белүгә ирешү;

- телдән белдерелгән фикерләрне язмача оештыруны камилләштерү;

## Программаның эчтәлеге

| № | Тема | Контроль эшләр | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | Белем һәм тормыш. | Сүзлек диктанты – 1 | 6 |
| 2 | Шушы яктан, шушы туфрактан без... | Директор контроль эше - 1 | 4 |
| 3 | Зарарлы гадәтләрдән сакланыгыз. | Сүзлек диктанты – 1 | 4 |
| 4 | Дустың булмаса—эзлә, тапсаң —югалтма. | Директор контроль эше - 1 | 8 |
| 5 | Саф хисләр — беренче хисләр. | Сочинение -1 | 6 |
| 6 | Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. | Изложение – 1<br>Арадаш аттестация эше -1 | 7 |
| | Барлыгы | Сүзлек диктанты -2<br>Директор контроль эше -2<br>Сочинение -1<br>Изложение – 1<br>Арадаш аттестация эше -1 | 35 |

## Укучының белем дәрәҗәсенә таләпләр

1. Татар теленең һәм әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны турында мәгълүмат алу;
2. Татар һәм рус телләрендәге аерым грамматик категорияләрнең тәңгәл килү-килмәвен белү;
3. Татар теленең орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик, пунктицион нормаларын белү һәм, аларга нигезләнеп, телдән яки язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;
4. Аралашу ситуацияләренә бәйле лексик берәмлекләрне, аларның синонимнарын һәм антонимнарын төгәл һәм урынлы куллана белү;
5. Татар теленең фразеологик берәмлекләрен таный һәм сөйләмдә куллана белү;
6. Гади һәм кушма җөмләләрнең төрен белү;
7. Татар җөмләсендә сөйләм яңалыгының хәбәр алдында урнашуын белеп, оештыру осталыгына ия булу;
8. Татар һәм рус телләре арасындагы тарихи, мәдәни бәйләнешләр турында белү;
9. Төрле чыганаклардан ( фәнни-популяр текстлар, массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет һ.б.) файдаланып, кирәкле мәгълүматны таба һәм башкаларга телдән яки язмаса җиткерә алу;
10. Мәдәниара аралашу ситуацияләрендә әңгәмә кора алу;

11 Тиешле күләмдә татар сүзләрен яттан белеп, аларны телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллана белү.

## 10 нчы сыйныф, рус төркеме (әдәбият)

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән Р.З. Хәйдарова, К.С. Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” буенча 10 нчы сыйныфта татар теле һәм әдәбиятына 102 сәгать каралган. Мәктәпнең еллык календарь укыту графигы буенча 10 нчы сыйныфларда 35 атна булу сәбәпле, эш программасы белем бирү учреждениесенең 2014-2015нче елга гамәлдәге планы буенча атнага 3 сәгать исәбеннән , ягъни татар теленнән 35 , әдәбияттан 70 сәгатькә төзелде.

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы

“Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013

Дәреслек: З.Хәйдәрова. Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10 нчы сыйныфы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен), Казан, Мәгариф, 2009 ел.

Фәнне өйрәтүнең төп максаты – гамәли максат: телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле сөйләм ситуацияләре кысаларында белем бирү һәм күнекмәләрен үстерү. Гомуми белем бирү максаты укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камилләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. Тәрбияви максат балаларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә.

Татар әдәбиятын укытуның максатлары:

матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;

тиз үзгәрүчән заман шартларында файдалы җитештерүчән хезмәткә яраклы, үз-үзен танып белергә һәм һәрдаим камилләштерергә әзер, рухи дөньясы бай булган шәхес тәрбияләү; гуманлылык карашлары,милли үзаң, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт булдыру;

укучыларда әдәбиятның үзенчәлекләре турында карашларны, әдәби текстны кабул итү, образлы һәм аналитик фикерләү культурасын, автор позициясен аңлау, әдәби процессның тарихи һәм эстетик нигезләренә төшенү , эстетик һәм иҗади сәләтне, кызыксынуны үстерү;

телдән һәм язма сөйләмне үстерү;

әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрне тарихи-әдәби җирлеген аңлап һәм сәнгати кыйммәте бөтен тулылыгында гына

ачыкланучы буларак анализлау һәм шәрехләү; төрле типтагы сочинениеләр язу; кирәкле мәгълүматларны (Интернет челтәре аша

да) табу, системалаштыру һәм файдалану күнекмәләре булдыру;

туган әдәбиятта һәм башка халыклар әдәбиятында чагылыш тапкан әхлакый идеалны үзара бәйләнештә аңлау һәм әдәби-сәнгати фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне ачыклау;

Бурычлар:

лексик-грамматик белемнәрне системалаштыру;

татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештыру күнекмәләрен үстерү;
программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзи белүгә ирешү; телдән белдерелгән фикерләрне язмача оештыруны камилләштерү
Укучының белем дәрәҗәсенә таләпләр

Тыңлап аңлау. Укучыларның җанлы сөйләмне тыңлап аңлау күнекмәләрен камилләштерү; тыңланган мәгълүматка нигезлзнеп, күмәк аралашуда катнашу.
Сөйләү. Аралашу барышында коммуникатив максатка ирешү һәм үз фикерләрен эзлекле итеп белдерү; тормыштагы вакыйгалар, күренешләр турында хәбәр итү һәм фикер йөртү; укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген мөмкин кадәр эзлекле һәм аңлаешлы итеп сөйләү.
Уку. Танышу, эзләнү, өйрәнү, карап чыгу максаты белән уку төрләреннән файдаланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку һәм интернет аша кирәкле мәгълүматны табып уку күнекмәләренә ия булу; укылган текстның эчтәлеген эзлекле итеп сөйләп бирү;
Язу һәм язма сөйләм. Бәйләнешле текстларны рус теленнән татарчага язмача тәрҗемә итү; тәкъдтм ителгән тема буенча чыгыш ясау өчен тезислар язу; аралашу ситуацияләрендә сөйләм үрнәкләреннән һәм гыйбарәләреннән файдалану.
татар әдәбиятының дөньякүләм тоткан урыны, татар әдәбияты классиклары, аларның әсәрләре турында мәгълүмат;
сүз сәнгатенең образлы табигате турында;
өйрәнгән әдәби әсәрләрнең эчтәлеге;
классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп факторы;
төп әдәби-теоретик төшенчәләр;
әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләп аңлату;
әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү;
автор позициясен ачыклау;
әдәби бәйләнеш таләпләрен саклаган хәлдә өйрәнелгән әсәрләрне (яки өзекләрне) сәнгатьле итеп уку;
әдәби әсәргә дәлилле рәвештә үз мөнәсәбәтен белдерү;

Программаның эчтәлеге

Белем һәм тормыш.

Шушы яктан,шушы туфрактан.

Зарарлы гадәтләрдән сакланыгыз.

Дустың булмаса—эзлә, тапсаң —югалтма.

Саф хисләр — беренче хисләр.

Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый.

## 11 нче сыйныф, рус төркеме (татар теле)

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

15. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
16. “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013
17. Дәреслек: Дәреслек:Р.З.Хәйдәрова , Р.Л.Малафеева “Татар теле 11 нче сыйныф” Казан, “Мәгариф” нәшрияты 2010 нчы ел,(рус телендә сөйләшүче балалар өчен).

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле буенча системалы фәнни белем бирү, аларны ирекле аралашырга өйрәтү, татар дөньясы турында күпкырлы мәгълүмат җиткерү **төп максат** итеп билгеләнә.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** үтәлергә тиеш:
1) татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
2) татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
3) программада күрсәтелгән темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
4) карап чыгу, танышу,өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
5) фразеологик берәмлекләрнең, мәкальләрнең рус эквивалентларын табарга һәм чагыштырырга өйрәтү;
6) татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү
8) татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
9) халыкларның үзара аңлашып яшәвенә омтылыш тәрбияләү .

Уңышка ирешү өчен тел дәресләрен әдәбият дәресләре белән тыгыз алып бару отышлы. Татар теле дәресләрендә өйрәнелгән грамматик структуралар әдәбият дәрес ләрендә сөйләмдә ныгытыла, лексик материал активлаштырыла. Дәресләрдә кулланыла торган текстлар татар этнокультурасын, тарихын, гореф-гадәтләрен чагылдыра.

Укучылар 11 нче сыйныфта татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен, диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү өстендә эшне дәвам итәләр; дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру, татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү өстендә эшлиләр.

### 11 нче сыйныф укучылары өчен үзләштерергә тиешле белем- күнекмәләр:

1. Җөмләләрнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, сорау куя, аера белү.
2. Кушма һәм гади җөмләләрне аера белү.
3. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру.
4. Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.
5. Иярчен хәл җөмләләрнең иярчен вакыт җөмлә, урын җөмлә, рәвеш җөмлә, күләм җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, сәбәп җөмлә, кире җөмләләрен танып белү һәм аларны сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.
6. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую һәм аларны тиешле интонация белән әйтә белү.

### Программаның эчтәлеге

| № | Бүлекләр, темалар | Сәгать саны | Контроль эшләр |
|---|---|---|---|
| 1 | **Алда юллар, кайсын сайларга?** | 9 | **1.Кереш контроль эш.**<br>2.Сүзлек диктанты |
| 2 | **Татарстан тарихы** | 3 | **1.Изложение**<br>**2.Директор контроль эше** |
| 3 | **Әдәбият –сәнгать дөньясында** | 3 | |
| 4 | **Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше** | 3 | |
| 5 | **Гаилә һәм балалар** | 8 | **Директор контроль эше** |
| 6 | **Беренче хисләр, гаилә кору** | 7 | **1.Сочинение. Әдәби әсәр героена хат язу**<br>**2.Контроль эш(арадаш аттестация)** |
| 7 | **Телләр белгән – илләр гизгән** | **1** | |
| | **Барлыгы** | **34** | |

**11 нче сыйныф, рус төркеме (әдәбият)**

Эш программасы түбәндәге документларга таянып төзелде:

1. Менделеев шәһәре 1 нче гимназиясенең 2014- 2015 нче уку елы өчен уку-укыту планы
2. “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче – авторлары: Р.З.Хәйдарова, К.С.Фәтхуллова, Г.М.Әхмәтҗанова – Казан: 2013
3. Дәреслек: Дәреслек:Р.З.Хәйдәрова , Р.Л.Малафеева “Татар теле 11 нче сыйныф”

Казан, “Мәгариф” нәшрияты 2010 нчы ел,(рус телендә сөйләшүче балалар өчен).

Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле буенча системалы фәнни белем бирү, аларны ирекле аралашырга өйрәтү, татар дөньясы турында күпкырлы мәгълүмат җиткерү **төп максат** итеп билгеләнә.

Максатка ирешү өчен, түбәндәге **бурычлар** үтәлергә тиеш:

1) татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
2) татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
3) программада күрсәтелгән темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
4) карап чыгу, танышу,өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
5) фразеологик берәмлекләрнең, мәкальләрнең рус эквивалентларын табарга һәм чагыштырырга өйрәтү;
6) татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү
8) татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
9) халыкларның үзара аңлашып яшәвенә омтылыш тәрбияләү .

**11 нче сыйныф укучыларының белем дәрәҗәләренә таләпләр.**

**Тыңлап аңлау**

Төрле төрдәге тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;

зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән әдәби әсәрләрдән өзекләрне, информацион характердагы текстларны, газета-журналлардан мәкаләләрне тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;

Сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

**Диалогик сөйләм**

Сорау, җавап, килеш(мә)ү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;

аралашуда катнаша, аны туктата һәм яңадан башлый белү;

парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата,раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

терәк схемалар кулланып, ситуация буенча әңгәмә кора белү;

татар сөйләм этикеты үрнәкләреннән урынлы файдаланып әңгәмә кору, сөйләшә белү.

**Монологик сөйләм**

Программада тәкъдим ителгән темалар буенча тиешле эзлеклелектә текст төзи һәм аның эчтәлеген сөйли белү;

конкрет ситуациягә үз карашыңны, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

монологик сөйләмдә кереш, эндәш сүзләрне кулланып, орфоэпик һәм грамматик нормаларны саклап, үз фикереңне төгәл җиткерә белү;

өйрәнгән текстны үз сүзләрең белән сөйләп бирә белү;

өйрәнгән шигырьләрне яттан сәнгатьле сөйли белү.

**Уку**

Программада тәкъдим ителгән текстларны, татар теленең әйтелеш нормаларын саклап, сәнгатьле һәм аңлап уку;

текстның эчтәлегенә нигезләнеп, контекст буенча яңа сүзләрнең мәгънәсен аңлый белү;

таныш булмаган текстны эчтән укып, аның төп фикерен таба белү;

таныш булмаган сүзләрнең, төзелмәләрнең тәрҗемәсен сүзлектән таба белү.

**Язу**

Өйрәнелгән темалар буенча актив куллануда булган сүзләрне дөрес яза белү;

конкрет бер тема буенча хикәя төзи белү;

прагматик текстлар (рецептлар, белдерүләр, афиша һ.б.), эпистоляр жанр текстлары (шәхси һәм официаль хатлар, котлаулар һ.б.) яза белү;

үзеңне борчыган проблемага карата үз фикерләреңне язмача җиткерә белү;

тәкъдим ителгән текстның эчтәлегенә нигезләнеп, аны үзгәртеп яки дәвам итеп яза белү.

Аралашу ситуацияләренә карата фикерләрне язмача белдерә алу; укылган текстның планын төзи алу;

өйрәнелгән әсәр эчтәлегенә нигезләнеп, сочинение яза алу; тәкъдим ителгән темага реферат яза алу;

**Программаның эчтәлеге**

Алда юллар, кайсын сайларга?
Татарстан тарихы

Әдәбият –сәнгать дөньясында

Спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше
Гаилә һәм балалар
Беренче хисләр, гаилә кору
Телләр белгән – илләр гизгән